ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«17» февраля 2020 ел **№ 100**

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының "2019-2021 елларга Арча муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча муниципаль программаны раслау турында" 2019 елның 15 февралендәге 80 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Экстремистлыкка каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы, «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законнар, аларга кертелгән үзгәрешләр, Арча районы прокуратурасының мәгълүмати хаты нигезендә, 2019-2023 елларга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы торуның комплекслы планын үтәү йөзеннән, террорчылыкка һәм экстремистлыкка каршы юнәлештәге профилактик чаралар системасын камилләштерү максатыннан КАРАР БИРӘМ:

1. 2019-2021 елларга Арча муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча муниципаль программага үзгәрешләр кертергә һәм "2019-2021 елларга Арча муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чараларын финанслау" дигән 9 бүлекне кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Арча муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе, башка җаваплы башкаручыларга әлеге Программа чараларының үтәлешен тәэмин итәргә.

3. «Арча муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә район бюджетын чираттагы финанс елына формалаштырганда, Программаны тормышка ашыру срокларын исәпкә алып, Программа чараларын финанслау ассигнованиеләрен күздә тотарга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны террорчылыкка каршы комиссия секретаренә йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә. Галимуллин

*Арча муниципаль районы башкарма комитетының «17» февраль 2020 ел, №100 карарына кушымта*

**9. 2019-2021 елларга Арча муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Программа чараларын финанслау**

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | Район бюджеты акчалары хисабына финанслау-мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2019 | 2020 | 2021 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| **Максат:** Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның тормыш куркынычсызлыгын һәм тынычлыгын, аларның экстремистлыкка һәм террорчылыкка каршы торуга законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау дәрәҗәсен күтәрү, районда әлеге күренешләрне кисәтү һәм булдырмау | | | | | | | | | |
| 1нче бурыч. Милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, социаль, этник һәм конфессия низагларын профилактикалау һәм булдырмау | | | | | | | | | |
| 1.1. Милләтара һәм конфессияара низаглар тудыру билгеләрен ачыклау буенча басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары, укыту-методик әдәбият һәм башка басма материалларны өйрәнү | Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча) | 2019-2021 | террорчылар һәм экстремистларга җәза бирүне гадел чара буларак бәяләүче халык өлеше-процент | 60 | 65 | 70 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 1.2. Экстремистлык һәм террорчылык эшчәнлеген оештыруга һәм гамәлгә ашыруга катнашы булган затлар һәм төркемнәр турында мәгълүмат җыю | Арча муниципаль районы АТК каршындагы террорчылыкка һәм | 2019-2021 | террорчылар һәм экстремистларга җәза бирүне гадел чара | 60 | 65 | 70 | Чара оештыру характерына ия, финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| максаты белән мәгълүмати ресурсларда, шул исәптән Интернет челтәрендә мониторинг алып бару | экстремистлыкка мәгълүмати каршы тору буенча пропаганда төркеме, "ФОРПОСТ", Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча) | | буларак бәяләүче халык өлеше-процент | | | | |
| 1.3. Муниципаль берәмлек территориясендә халыкның миграция торышына мониторинг оештыру | Авыл җирлекләре башлыклары | Ярты елга бер тапкыр 2019-2021 | террорчылар һәм экстремистларга җәза бирүне гадел чара буларак бәяләүче халык өлеше-процент | 60 | 65 | 70 | Чара оештыру характерына ия, финанслау таләп ителми |
| 1.4. Белем бирү учреждениеләрендә террорчылык һәм экстремистлык күренешләрен кисәтү һәм балигъ булмаган укучы балаларны һәм яшьләрне экстремистлык эшчәнлегенә җәлеп итүгә каршы тору буенча максатчан чаралар үткәрү | Башкарма комитетның "Мәгариф идарәсе" МУ, «Мәдәният идарәсе» МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, «Татмедиа» АҖ филиалы-«Арча-Информ» (килешү буенча), Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча) | 2019-2021 | террорчылар һәм экстремистларга җәза бирүне гадел чара буларак бәяләүче халык өлеше-процент | 60 | 65 | 70 | Чара оештыру характерына ия, финанслау таләп ителми |
| 1.5. Деструктив сайтларда теркәлгән затлар белән эш оештыру | Арча муниципаль районы АТК каршындагы террорчылыкка һәм экстремистлыкка мәгълүмати каршы | 2019-2021 | деструктив сайтларда теркәлгән абунәчеләр саны | 294 | 250 | 200 | Чара оештыру характерына ия, финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тору буенча пропаганда төркеме, "ФОРПОСТ", Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча) | | | | | | |
| 1.6. Районның дини оешмаларында җомга намазлары вәгазе вакытында дин тотучыларда террорчылык һәм экстремистлыкны бәяләү һәм андый хәлләргә түзеп тормаучанлык формалаштыру, әлеге күренешләрнең дини низагларны булдырмау чарасы түгеллеген аңлату эшләре алып баруны оештыру | Арча районы мөхтәсибәте (килешү буенча) | 2019-2021 | террорчылар һәм экстремистларга җәза бирүне гадел чара буларак бәяләүче халык өлеше- процент | 60 | 65 | 70 | Чара оештыру характерына ия, финанслау таләп ителми |
| 1.7. Районның гомуми белем бирү оешмаларында «Куркынычсызлык айлыгы» уздыру, террорчылык акты турында ялган хәбәрләр таратуны булдырмау буенча дәресләр һәм балалар һәм яшүсмерләрнең хокук бозуларын профилактикалау буенча лекцияләр үткәрү | Башкарма комитетның "Мәгариф идарәсе" МУ, «Мәдәният идарәсе» МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча) | Ярты елга бер тапкыр 2019-2021 | террорчылар һәм экстремистларга җәза бирүне гадел чара буларак бәяләүче халык өлеше- процент | 60 | 65 | 70 | Чара оештыру характерына ия, финанслау таләп ителми |
| 1.8. Террорчылыктан саклануны тикшерү һәм чит кешеләрнең яшәү фактларын ачыклау максатыннан, торак пунктлар территорияләрен, шул исәптән ташландык һәм халык аз яши торган урыннарны, подвал һәм чарлак бүлмәләрен тикшерү буенча рейдлар оештыру һәм үткәрү | Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча), «Арча МР идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять (килешү буенча), җирлек башлыклары | Кварталга кимендә 1 тапкыр 2019-2021 | террорчылар һәм экстремистларга җәза бирүне гадел чара буларак бәяләүче халык өлеше- процент | 60 | 65 | 70 | Чара оештыру характерына ия, финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.9. Террорлык эшчәнлегенә катнашы булган (гамәлдәге, хөкем ителгән), шул исәптән террорчылык активлыгы югары булган илләрдән кайткан затларның гаилә әгъзалары белән террорчылык эшчәнлегендә катнашкан һәм террорчыларга ярдәм иткән өчен җаваплылык билгели торган РФ законнары нормаларын аңлату, шулай ук күрсәтелгән затларга дини һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре, психологлар катнашында социаль, психологик һәм хокукый ярдәм күрсәтү буенча әңгәмәләр үткәрү | Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге ( килешү буенча), Арча МР ОМСы | кварталга кимендә 1 тапкыр 2019-2021 | террорчылар һәм экстремистларга җәза бирүне гадел чара буларак бәяләүче халык өлеше-процент | 60 | 65 | 70 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 1.10. Формаль булмаган берләшмәләрне ачыклау буенча рейдлар оештыру, теркәлмәгән дини һәм милли берләшмәләрне ачыклау буенча дини конфессияләр һәм милли диаспоралар вәкилләре белән әңгәмәләр үткәрү | Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча) | 2019-2021 | террорчылар һәм экстремистларга җәза бирүне гадел чара буларак бәяләүче халык өлеше-процент | 60 | 65 | 70 | Чара оештыру характерына ия, финанслау таләп ителми | | |
| **2 нче бурыч. Террорчылык һәм экстремистлык идеологиясе күренешләренә түзеп тормаучанлыгын булдыруга юнәлтелгән җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру** | | | | | | | | | |
| 2.1. Террорчылыкка каршы эчтәлекле мәгълүмат, шул исәптән Арча муниципаль районының рәсми сайтында видеоязмалар урнаштыру | Башкарма комитетның "Мәгариф идарәсе" муниципаль учреждениесе, “Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе, Яшьләр эшләре, туризм һәм спорт бүлеге, «Татмедиа» АҖ филиалы «Арча-Информ» (килешү буенча), Россия Эчке эшләр | 2019-2021 | хокук саклау органнарының террорчылык һәм экстремистлык күренешләренә каршы көрәшен тиешле чаралар буларак бәяләүче халык өлеше-процент | 50 | 55 | 60 | Чара оештыру характерына ия, финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | министрлыгының Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча) | | | | | | | | |
| 2.2. Милләтара һәм конфессияара низаглар турында хәбәр итү өчен массакүләм мәгълүмат чарларында «Кайнар линия" телефон номерларын бастырып чыгару | Авыл җирлекләре башлыклары, Арча муниципаль районы террорчылыкка каршы комиссиясе | Кварталга 1 тапкыр 2019-2021 | хокук саклау органнарының террорчылык һәм экстремистлык күренешләренә каршы көрәшен тиешле чаралар буларак бәяләүче халык өлеше-процент | 50 | 55 | 60 | Чара оештыру характерына ия, финанслау таләп ителми | | |
| 2.3. “Милләтара татулыкны ныгыту-террорчылыкка каршы торуның мөһим факты” темасына кинофильмнар күрсәтү, халык иҗаты коллективларының чыгышларын оештыру, спектакльләр күрсәтү, күргәзмәләр, түгәрәк өстәлләр, семинарлар үткәрү | Башкарма комитетның "Мәгариф идарәсе" МУ, “Мәдәният идарәсе” МУ | 4 квартал 2019-2021 | хокук саклау органнарының террорчылык һәм экстремистлык күренешләренә каршы көрәшен тиешле чаралар буларак бәяләүче халык өлеше-процент | 50 | 55 | 60 | Чара оештыру характерына ия, финанслау таләп ителми | | |
| 2.4. Террорчылыккага һәм экстремистлыкка каршы тору өлкәсендә җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү максатыннан социологик тикшеренүләр, анкеталар, сораштырулар үткәрүне оештыру | Арча районы башкарма комитеты, Арча МР АТК әгъзалары, «Татмедиа» АҖ филиалы-«Арча-Информ» (килешү буенча), «ФОРПОСТ" | 2019-2021 | хокук саклау органнарының террорчылык һәм экстремистлык күренешләренә каршы көрәшен тиешле чаралар буларак бәяләүче халык өлеше-процент | 50 | 55 | 60 | 1,0 | 1,0 | 1,0 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.5. Гадәттән тыш хәлләр, шул исәптән террорчылык характерындагы гамәлләр турында халыкка хәбәр итү максатларында, җәмәгать урыннарында урнаштыру өчен хокук саклау органнары һәм ашыгыч ярдәм күрсәтү хезмәтләре телефон номерлары белән күрсәтмә агитация (плакатлар, баннерлар) һәм конструкцияләр әзерләүне тәэмин итү | Арча муниципаль районы башкарма комитеты | 2019-2021 | хокук саклау органнарының террорчылык һәм экстремистлык күренешләренә каршы көрәшен тиешле чаралар буларак бәяләүче халык өлеше-процент | 50 | 55 | 60 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 2.6. Рухи-әхлакый кыйммәтләрне, Россия ватанпәрвәрлеген, РФ, ТР, Арча МР дәүләт символларын, милләтара һәм динара хөрмәт һәм үзара ярдәмне пропагандалаучы, шулай ук халыкның террорчылыкка һәм экстремистлыкка каршы торуда актив катнашуына ярдәм итүче район басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары тематик рубрикаларының чыгуын тәэмин итү | "Татмедиа» АҖ филиалы-"Арча-Информ" (килешү буенча) | 2019-2021 | хокук саклау органнарының террорчылык һәм экстремистлык күренешләренә каршы көрәшен тиешле чаралар буларак бәяләүче халык өлеше-процент | 50 | 55 | 60 | Чара оештыру характерына ия, финанслау таләп ителми | | |
| 2.7. "Экстремистлыкка-ЮК!» айлыгы оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның "Мәгариф идарәсе" МУ, «Мәдәният идарәсе» МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, "Татмедиа" АҖ филиалы-"Арча-Информ" (килешү буенча) | ел саен 3 нче кварталда<br><br>2019-2021 | хокук саклау органнарының террорчылык һәм экстремистлык күренешләренә каршы көрәшен тиешле чаралар буларак бәяләүче халык өлеше-процент | 50 | 55 | 60 | 20,0 | 20,0 | 20,0 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.8. Авыл җирлегендә үткәрелә торган җыелышларда (җыеннарда) террорчылыкка һәм экстремистлыкка каршы тору буенча күрелә торган чаралар турында мәгълүмат бирү | Авыл җирлекләре башлыклары, Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча) | 2019-2021 | хокук саклау органнарының террорчылык һәм экстремистлык күренешләренә каршы көрәшен тиешле чаралар буларак бәяләүче халык өлеше-процент | 50 | 55 | 60 | Чара оештыру характерына ия, финанслау таләп ителми | | |
| 3 нче бурыч. Районда объектларның террорчылыктан сакланышын тәэмин итү | | | | | | | | | |
| 3.1. Мәдәният, мәгариф һәм спорт объектларының террорчылыктан сакланышы буенча чаралар үткәрү | Башкарма комитетның "Мәгариф идарәсе" МУ, «Мәдәният идарәсе» МУ, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | 2019-2021 | Объектларда террорчылыкка каршы саклану чараларының үтәлеше | 70 | 80 | 90 | 1239,0 | 1339,0 | 1439,0 |
| **Программа буенча барлыгы:** | | | | | | | 1290,0 | 1390,0 | 1490,0 |